ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенең Караталга торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2023 елның 4 декабрендәге №5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенең Караталга торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенең Караталга торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, көндезге уку формасы буенча белем алучы, өлешчә мобилизацияләү буенча мобилизацияләнгән студентлардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (шул исәптән сатып алу, ташу, вак таш салу, юлларны кышкы тоту, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (шул исәптән җәйге вакытта территорияне кисү, кыргый үскән куакларны һәм агачларны кисү, КРН-2,1 ротация чапкычының запас өлешләрен сатып алу, ягулык-майлау материалларын сатып алу);

3) беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (шул исәптән янгын гидрантларын тоту, янгын кранын җылыту, люкларны кардан һәм боздан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу).

"КАРШЫ" «ӨЧЕН».

3. Әлеге карарны Иске Казиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://kamskoye-ustye.tatarstan.ru/), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казеево
авыл җирлеге башлыгы И.Х.Сәгъдиев